РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 52 2020 елның 29 июне

## Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Елантау авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 2 номерлы карары белән расланган «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең график өлешенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 3569 кв. м мәйданлы җир кишәрлеге территориаль зонасын 16:30:140501:197 кадастр номерлы махсус билгеләнештәге СН-2 яшелләндерү зонасыннан Кармалы авылы белән янәшә 16:30:140501:284 кадастр номерлы җир кишәрлегендә гамәлдәге зиратны киңәйтү өчен СН-1 махсус билгеләнештәге зонага үзгәртергә (кушымта);

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларының матбугат басмаларында, Түбән Кама муниципаль районы һәм Кармалы авыл җирлеге рәсми сайтларында бастырып чыгарырга.


3. «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, кертелгән үзгәрешләр белән, Россия Федерациясе территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасына (РФ ТП ФДМС) һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.


4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләнә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы А.Р.Метшин

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2020 елның 29 июнендә 52 номерлы
карарына кушымта

Кармалы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналаштыру картасыннан выкопировка




Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы урынбасары Р.И.Хәбибуллин